ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 елның «28» августыннан № 427

**«2017 елда Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Яңа Чишмә муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында сыерларга хезмәт күрсәтү буенча ветеринария-профилактика чараларын үткәрүгә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы һәм «Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» 2003 елның 11 июнендәге 74-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, карар бирәм:

1. 2017 елда Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Яңа Чишмә муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында сыерларга хезмәт күрсәтү буенча ветеринария профилактика чараларын уздыруга субсидияләр бирү тәртибен кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

Татарстан Республикасы Яңа
Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2017 елның «28» августыннан
427 номерлы карары белән
расланган

2017 елда Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Яңа Чишмә муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында сыерларга хезмәт күрсәтү буенча ветеринария профилактика чараларын уздыруга субсидияләр бирү тәртибе

1. 2017 елда Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан махсус оешмаларга Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Яңа Чишмә муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында сыерларга хезмәт күрсәтү буенча ветеринария профилактика чараларын уздыруга субсидияләр бирү механизмын билгели(алга таба – субсидияләр, махсуслаштырылган оешма).

2. Субсидияләр бирү 2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре, 2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет язмасы һәм Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитетына расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә (алга таба – район башкарма комитеты), әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга гамәлгә ашырыла.

3. 2017 елда Яңа Чишмә муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында сыерларга хезмәт күрсәтү буенча ветеринария-профилактика чараларын үткәрүгә каралган акчаларны баш бүлүче булып район Башкарма комитеты тора.

4. Район Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында ачылган шәхси счеттан субсидия алучыларның исәп-хисап счетларына акча күчерүне башкара.

5. Субсидияләр алучыларны сайлап алу критерие булып йогышлы, инвазион, иярмәүче авыруларга лаборатор-диагностик тикшеренүләр уздыруга эшчәнлек алып бару; биохимик, токсикологик, микологик һәм башка профилактик чаралар үткәрү тора.

6. Субсидия алучының субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айның беренче числосына түбәндәге таләпләргә туры килгән очракта бирелә:

субсидия алучы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

-үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында тормый һәм хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләр юк;

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында дәүләт яки территориядә теркәлгән чит ил юридик затлары өлеше 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булып тормый;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне кире кайтару буенча кичектерелгән бурычлары һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты каршында кичектерелгән бүтән бурычлары юк;

Россия Федерациясе законнары нигезендә башкару срогы җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары юк.

7. Мөрәҗәгать итүчегә субсидияләр тикшерелгән бер сыер башына 192 сумнан артык булмаган күләмдә бер мәртәбә бирелә.

8. Авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары район Башкарма комитетына, шәхси ярдәмче хуҗалыклар исемлеге һәм ветеринария профилактикасы чараларын уздырырга кирәк булган сыерлар саны кушымтасы белән, авыл җирлеге башлыгы тарафыннан имзаланган заявканы ирекле рәвештә язылган гариза җибәрәләр..

9. Район Башкарма комитеты авыл җирлекләреннән кергән гаризаларны 5 эш көне эчендә карый, Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе кул куйган хат эзерли һәм гаризалар белән бергә ветеринария профилактикасы чараларын уздыруны гамәлгә ашыручы оешмага җибәрә.

10. 2017 елда шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сыерларга хезмәт күрсәтү буенча ветеринария-профилактика чараларын үткәрүгә 2017 елда шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сыерларга хезмәт күрсәтү буенча ветеринария профилактика чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга субсидияләр бирү шартлары булып түбәндәгеләр санала:

субсидия алучыларның юридик затларның бердәм дәүләт реестрында дәүләт теркәве турында таныклыгыбулуы;

йогышлы, инвазион, иярмәүче авыруларга лаборатор-диагностик тикшеренүләр уздыруга лицензия булу; биохимик, токсикологик, микологик һәм башка профилактик чаралар;

2017 елда шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сыерларга хезмәт күрсәтү буенча ветеринария-профилактика чараларын үткәрү буенча хезмәтләр күрсәтү.

11. Субсидияләр алу өчен, алучылар район Башкарма комитетына түбәндәге документларны тапшыралар:

әлеге карар белән расланган форма буенча субсидияләр бирү турында 1 нче кушымта нигезендә үзенең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, шул исәптән түбәндәгеләр турында мәгълүматны үз эченә алган гариза:

үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында тормый һәм хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләр юк;

оешма чит ил юридик заты булып тормый, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс

операцияләре (офшор зоналары) үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләттә яки территориядә теркәлгән чит ил юридик затларының устав (җыелма) капиталында катнашу өлеше барысы бергә 50 процентан арткан Россия юридик заты булып тормый;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне кире кайтару буенча кичектерелгән бурычлары һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты каршында кичектерелгән бүтән бурычлары юк;

затның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәү вакыты килеп җиткән бурычлары юк;

субсидия алучы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

әлеге карар белән 2 нче кушымта нигезендә расланган форма буенча тиешле субсидияләр турында белешмә-исәп;

2017 елда халыкның шәхси ярдәмче хуҗалыкларында сыерларга хезмәт күрсәтү буенча ветеринария-профилактика чараларын үткәрүне раслый торган тиешенчә рәсмиләштерелгән документлар (хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр, башкарылган эшләр актлары, түләүгә һәм экспертизага счет)

12. Район Башкарма комитеты:

битләренә номерлар сугылган, мөһер беркетелгән журналга субсидияләр бирү турында гаризаларны кергән көнне теркәп бара;

гаризаны теркәгәннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 15 көнлек срокта:

тапшырылган документларны әлеге Тәртипнең 11 пуктларына туры килү-килмәүгә карый һәм субсидия бирү яисә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

алучылар белән әлеге Тәртип белән расланган форма һәм сроклар буенча субсидия бирү турында килешү төзи. Субсидия бирү турында килешүдә субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре, субсидия бирү күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирү тәртибе, формасы һәм сроклары күрсәткечләре күздә тотыла. Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеге район Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

Субсидия бирүдән баш тартуга нигез булып түбәндәгеләр тора:

тулы булмаган документлар җыелмасын тапшыру яки аларның әлеге тәртип таләпләренә туры килмәве;

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес тугеллеге;

бюджет йөкләмәләре лимитының булмавы.

Бюджет йөкләмәләре лимиты җитмәгән очракта, субсидияләр гаризалар бирү чираты тәртибендә бирелә.

Субсидияләр бирүдән баш тарткан очракта, Башкарма комитет әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән сроктан соң биш көн эчендә субсидия алучыга баш тарту турында белдерү җибәрә.

13.Башкарма комитет Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында

ачылган шәхси счетыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек чорда акчаларны кредит оешмаларында ачылган алучыларның исәп-хисап счетларына күчерә.

14. Бирелгән субсидияләр Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты керемена бюджет законнары нигезендә әлеге Тәртиптә һәм субсидияләр бирү турындагы килешүдә билгеләнгән тәртибен һәм шартларын бозу фактлары ачыкланган очракта, тиешле таләп алынган көннән алып 60 көн эчендә кайтарылырга тиеш.

15. Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты керемена ирекле кире кайтарудан баш тартканда, әлеге Тәртипнең 12 һәм 14 пунктларында күрсәтелгән очракларда алар закон нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

16. Яңа Чишмә муниципаль районының Контроль-хисап палатасы һәм муниципаль финанс контроле органнары законнар нигезендә алучылар тарафыннан субсидияләр бирү шартлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерәләр.

17. Вәкаләтле органга субсидияләр алучылар тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык тиешле субсидия алучы вазифаи затларга һәм җитәкчеләргә йөкләнә.

18. Бюджет акчаларыннан файдалануны тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы гамәлгә ашыра.

---

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы

Яңа Чишмә муниципаль районы

Башкарма комитеты җитәкчесе

Р.Р. Фасаховка

кемнән ______________________
(оешманың исеме)

_____________________________,
( оешмасы җитәкчесенең ФИО)

_____________________________

нигезендә эш итүче

Гариза

«Яңа Чишмә муниципаль районы шәхси ярдәмче хуҗалыкларында сыерларга хезмәт күрсәтү буенча ветеринария-профилактика чараларын үткәрүгә субсидияләр» статьясы буенча тиешле акчаларны ____________________ күләмендә исәп-хисап счетына күчерүегезне сорыйм.

Оешманың түләү реквизитлары:
Субсидия алучы: ________________________________
ИНН/КПП
_______________________________________________________________
х / с __________________________
Банк исеме _________________________________________
Корр.
хисап:___________________________________________________________________
_
БИК ___________________________
ОКТМО (муниципального берәмлек) ________________________________
Урнашу урыны буенча адресы: _______________________________
Фактта урнашу урыны адресы: __________________________________
Җитәкченең контакт телефоны: ______________________________________
E-mail: ______________________________________
Шулай ук 2017 елның 1 __________________ гә булуын да раслыйм.
(ай)

_____________________________________________________________________
(оешманың исеме)

-үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында тормый һәм хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чикләүләр юк;

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик

затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында дәүләт яки территориядә теркәлгән чит ил юридик затлары өлеше 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булып тормый;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләре, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләрне кире кайтару буенча кичектерелгән бурычлары һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты каршында кичектерелгән бүтән бурычлары юк;

Россия Федерациясе законнары нигезендә башкару срогы җиткән Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары юк.

__________________/ ____________________ «___» ________ 2017 ел

(җитәкченең имзасы) ФИА (дата)

Мөһер (булган очракта)

2 нче кушымта

Раслыйм:
ТР Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе

___________________ _________________________
(имзасы) (Ф.И.А.)
«___» ________ 2017 ел

2017 елда Яңа Чишмә муниципаль районы бюджетыннан Яңа Чишмә муниципаль районының шәхси ярдәмче хуҗалыкларында сыерларга хезмәт күрсәтү буенча ветеринария профилактика чараларын уздыруга субсидияләр бирү өчен
җыелма белешмә-исәп

| № т/б | Авыл җирлеге исеме | Шәхси ярдәмче хуҗалыклар саны | Тикшерелгән сыерларның баш саны, башларда | Субсидияләү ставкасы, 1 башка сум, сумнарда | Тиешле субсидиянең суммасы меңсум (4 гр. х5 гр.) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |

Белешмәләрнең дөреслеген раслыйбыз:
Субсидия алучы оешма җитәкчесе:
субсидияләр: _________________ _________________________
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Баш хисапчы _________________ _________________________
Мөһер (булганда) (имза) (Ф.И.О)